ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 503 от «13» 12 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 06 июнендәге «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 234 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары (13.01.2023 елгы ред.) нигезендә, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны тәртипкә китерү, халыкка сәүдә хезмәте күрсәтүне оештыруны һәм сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру максатында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты
карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 06 июнендәге «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 234 номерлы карарының 2 нче кушымтасындагы «Мамадыш муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокукны сату буенча аукцион оештыру һәм уздыру турында нигезләмә»нең 5 пунктындагы «Аукционда катнашучыларга таләпләр» 5.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гариза бирүче-аукционда катнашучы теләсә кайсы юридик зат, оештыру-хокукый формасына, милек формасына, урнашу урынына, шулай ук капиталның килеп чыгышы урынына яисә шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән физик зат, үзмәшгуль гражданнар була ала».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам..

Җитәкче О.Н.Павлов

0000012125